ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2023 елның 1 ноябре №148

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 62 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 62 номерлы «Физик затларның милкенә салым турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктның 1 пунктчасында:
икенче абзацта «4.1 пунктчасында» сүзләрен «4 һәм 4.1 пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;
өченче абзацта «, бирелгән» сүзен һәм «, дача» сүзен төшереп калдырырга;
дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Биеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Биеш авыл
җирлеге башлыгы -
Биеш авыл җирлеге
Советы рәисе Р.А. Валиев